Каралды
Башлангыч сыйныф укытучыларының мәктәп методик берләшмә җитәкчесе ______ Тухбатуллина Э.М.
Беркетмә № 1
« 26 » август 2017 ел.

Килешенгән
Укыту эшләре буенча директор урынбасары
______ Исмагилова Г,Т,.
"28" август 2017 ел

Раслыйм
Мәктәп директоры
______ Сабирзянова Г.Т..
Приказ № 71
« 28 » август 2017 ел

ТР Сарман муниципаль районы МБГББУ"Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе"

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

**4 нче а сыйныфы**

**Салихова Нурия Миргасыйм кызы,** югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы

Каралды
Мәктәп педагогик советы утырышы беркетмәсе №1
28 август 2017 ел

**2017 – 2018 нче уку елы**

Рассмотрено
Руководитель методического объединения учителей начальных классов
________ Тухбатуллина Э.М.
Протокол № 1от
«26» августа 2017 г

Согласовано
Заместитель директора по учебной работе
___________ Исмагилова Г.Т..
«28» августа 20 17 г.

Утверждено
Директор школы
_______ Сабирзянова Г.Т.
Приказ № 71 от
«28» августа 2017 г.

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Сармановская средняя общеобразовательная школа» Сармановского муниципального района Республики Татарстан

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

## ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК, 4-а класс

**Салихова Нурия Миргасимовна**, высшая квалификационная категория

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1 от
«28» августа 2017 г.

2017 – 2018 учебный год

**Аңлатма язуы**

4- а сыйныфы өчен эш программасы база дәрәҗәсендә белем бирү программасына нигезләнеп төзелде. Ул программасы "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1 июль); "2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы" (2004 ел, 11 октябрь); Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 ел, 1 декабрь); Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. - ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре, Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2010; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; МБББУ «Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе» белем бирү программасы, "Укыту курсы һәм предметының эш программаларын раслау һәм эшләү тәртибе структурасы" турындагы нигезләмә, мәктәпнең 2017-2018 нче уку елына базис укыту планына нигезләнеп эшләнде.

Программа үтәлү өчен түбәндәге укыту-методик әсбаплар кулланыла:

- И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова. Татар теле 4нчесыйныф: Дәреслек. Ике кисәктән тора - Казан: «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2014
- И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова. Татар теле. 4 нчесыйныф: Методик кулланма.- Казан «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2014.

**Укыту предметына гомуми характеристика.**

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш". Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата.

«Перспектив башлангыч мәктәп»нең 4 нче сыйныфы өчен төзелгән татар теле программасы укытуның максатын, бурычларын һәм эчтәлеген билгели. Тәкъдим ителә торган программада татар теленә өйрәтүнең төп максаты һәм бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнергә теләк уяту;
- үз милләтенә, теленә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.
- балаларга татар теленең төрлебулекләребуенчабелембиру:
- фонетика, орфоэпия, лексикага караган белемнәрнетирәнәйтү;
- телебезнең грамматикасы, орфографиясе, пунктуациясе буенча кунекмәләр булдыра башлау;
- сүз, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә өйрәтү;
- җөмлә төзүче баш кисәкләр белән таныштыру;
- җөмләләрнең мәгънәви-интонацион үзенчәлекләрен күзәтү;
- җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен кую;
- укучыларда дерес уку һәм язу кунекмәләре булдыру;
- фикер йөртү турындагы кечкенә текстлар төзергә өйрәтү.
- телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм кунекмәләре булдыру.
- укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү

**Предметның укыту планындагы урыны**

Программа елга 102 сәгатькә (атнага 3 сәгать) каралган. УМК "Перспективалы башлангыч мәктәп"

**Искәрмә:"**Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең "Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында " гы 29 нчы август, 2016 нчы елда педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нче санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килү сәбәпле, 4 нче а сыйныфында дәресләр сәгатьләрне берләштерү исәбенә программа үтәлә.

**IV нче сыйныфта татар теленнән үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр**

| Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә | Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итү | Тыңлап аңлау | Фикерләү белән бәйле күнекмәләр | Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1. Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.<br>2. Эшне планлаштырырга өйрәнү.<br>3. Эшнең дөреслеген тикшерү.<br>4. Эш сыйфатына бәя бирә белү. | 1. Дәреслек белән эш итә белү.<br>2. Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.<br>3. Балалар өчен нәшер ителгән китаплар, газета-журналларны, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек һәм аңлап уку.<br>4. Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.5. Текста очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.6. Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү. | 1. Укытучының өйрәнгән материалга нигезләнгән сөйләмен тыңлап аңлау.<br>2.Текстнытыңлаганнан соң, төп фикерне башкаларыннан аера белү.3. Татарча сөйләмне тыңлап, сүз һәм җөмлә чикләрен билгеләү.<br>4. Ишеткән сөйләмнең, җөм-ләнең эчтәлегенә төшенү. | 1.Уку мәсьәләсен куярга өйрәнү.2. Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.<br>3, Төшенчә, термин, кагыйдә,закончалыкларны аңлап кабул итү күнекмәсен булдыру.<br>4. Грамматик анализ төрләрен үзләштерә башлау:Сүз төзелешенә анализ;- сүз төркемнәренә морфологик анализ;<br>- сүзтезмәләргә анализ;<br>- гади җөмләгә анализ;<br>5. Тикшеренү ысуллары:<br>- модельләштерү;<br>-охшатып эшләү. | 1. Телдән сөйләм:Кагыйдәләрне аңлап эзлекле сөйли белү күнекмәсе;-Сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе;-Тәрҗемә итү күнекмәсе..<br>2. Язма сөйләм:<br>-күчереп язу;-бирелгән темага сочинение язу;-план нигезендә изложение язу;-татар этнокультурасына караган сүзләр кертеп, җөмләләр язу;-үзең, гаилә, мәктәп турында кечкенә хикәяләр яки котлау язу;-сүзлек диктанты – (10 -12 сүз)-контроль диктант 6(35-45 сүз);-изложение 2(50-55 сүз, язманың күләме 30-35 сүз)<br>-сочинение 1 (45-50 сүз) |

## Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен өйрәнү нәтиҗәсендә укучыларда белем алу осталыгы нигезе буларак **танып белү, коммуникатив, регулятив һәм шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре формалашачак.**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре (ТБУУГ)**

Укучылар өйрәнәчәк:
• мөһим бәйләнешләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштырырга;
• күнегүләрне мөстәкыйл эшләү алымнарын үзләштерергә;
• тәкъдим ителгән план буенча телдән аңлатырга;
• материаль объект, таблица, рәсем, схемалар, сүзлекләр кулланырга;
• бирелгән алгоритм буенча күнегүләр башкарырга;
• фикерләүдә логик чылбыр төзергә;
• уку мәсьәләләрен модельләштерүдә билгеләр (символлар) кулланырга.
*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
• *интернетны кулланып, мәгълүмат эзләргә;*
• *мөстәкыйль рәвештә нигезләмә һәм критерийлар сайлап, чагыштыру, сериация һәм классификация башкарырга;*
• *сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләр урнаштыруны үз эченә алган логик хикәяләү тө-зергә.*

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ)**

Укучылар өйрәнәчәк:
• партадаш күрше белән яисә төркемдә хезмәттәшлек итәргә;
• нинди дә булса предмет яисә объектка төрле карашлар булу мөмкинлеген аңларга;
• килешергә һәм уртак эшчәнлектә гомуми чишелешкә килергә;
• сораулар формалаштырырга.
*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
• *сораулар ярдәмендә партнердан өстәмә мәгълүмат алырга;*
• *монолог төзергә.*

**Регулятив универсаль уку гамәлләре(РУУГ)**

Укучылар өйрәнәчәк:
• таблица буенча кагыйдәнең дөреслеген тикшерегә;
• гамәлләрне таләп ителгән вакытта башларга һәм тәмамларга;
• кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга ияреп гамәлләр кылырга;
• максатка кагылышсыз гамәлләрдән тыелырга;
• сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштырырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
• *партадаш күршең белән хезмәттәшлектә яңа уку мәсьәләләрен куярга;*
• *уку эшчәнлегенең үзең өчен әһәмиятен, мәгънәсен һәм сарыф ителгән вакытны, көчне бәяләргә;*
• *ирешеләчәк нәтиҗәне алдан фаразларга;*
• *яңа уку мәсьәләсен чишүгә керешкәнче үз мөмкинлекләреңне мөстәкыйль бәяләргә.*

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре(ШУУГ)**

Укучыларда формалашачак:
• татар теле фәненә танып белү кызыксынуы;
• дәреслек геройларына һәм партадаш күршеңә ярдәм итү инициативасы;
• үз уңышларын/уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү;
• нормалардан тайпылышны күрү;

## Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр

### Тел системасы

### Фонетика, орфоэпия һәм графика

Татар теленнән башлангыч гомуми белем бирү баскычын (1–4 сыйныфлар) тәмамлаган укучы: аваз һәм хәрефләрне аера; ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә ала; хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана ала.

Укучыга дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча сүзгә мөстәкыйль рәвештә фонетик-график (аваз-хәреф) анализ ясарга өйрәнү, сүзгә ясалган фонетик-график анализның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге бирелә.

Укучы: үз сөйләмендә татар әдәби тел нормаларын саклый һәм әңгәмәдәшенең сөйләмендә бу нормаларның дәреслектә бирелгән материал күләмендә үтәлүен бәяли; сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба яки укытучысына һәм әти-әнисенә мөрәҗәгать итә ала.

### Сүз төзелеше (морфемика)

Бу бүлектә укучы: тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларын аерырга;  сүзнең тамыр һәм кушымчаларын (аффиксларын) табарга өйрәнә.

Укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен тикшерү һәм аның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге ала.

### Лексикология

Бу бүлектә укучы: мәгънәсе ачыклану таләп итәлә торган сүзләрне табарга; текст буенча сүзләрнең мәгънәсен аера яисә аны аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачыкларга өйрәнә.

Укучы, текстларда кабатлаулар булдырмас өчен, кирәкле синонимнар, антонимнар табу, текстта туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне билгеләү, аларның урынлы кулланылышын бәяләү, тәкъдим ителгән сүзләр арасыннан тиешлесен сайлап алу мөмкинлеге ала.

### Морфология

Бу бүлектә укучы: исемнәрнең сан, килеш һәм тартым белән төрләнешен; сыйфатларның лексик-семантик һәм морфологик-

синтаксик үзенчәлекләрен; фигыльнең лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнә.

Укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча исемгә, сыйфатка, фигыльгә морфологик анализ ясау һәм аның дөреслеген бәяләү, тексттан алмашлык, рәвеш, бәйлек сүзләр, кисәкчә, теркәгечләрне, фигыльләрдәге юклык кушымчаларын (-ма / -мә) табу мөмкинлеге ала.

**Синтаксис**

Бу бүлектә укучы: җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга; сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга; җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга; җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә; тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә өйрәнә.

Укучы җөмләнең иярчен кисәкләрен – аергыч, тәмамлык, хәлләрне аеру,дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча гади җөмләгә синтаксик анализ (җөмлә кисәкләре буенча) ясау һәм аны тикшерүнең дөреслеген бәяләү, гади һәм кушма җөмләләрне бер-берсеннән аеру мөмкинлеге ала.

**Орфография һәм пунктуация**

Бу бүлектә укучы: дөрес язылыш кагыйдәләрен өйрәнгән күләмдә кулланырга; сүзләрнең дөрес язылышын орфографик сүзлек буенча ачыкларга; 80–90 сүзле текстны дөрес итеп күчереп язарга; өйрәнелгән дөрес язу кагыйдәләренә туры килгән 70–80 сүзле текстны укытучы әйтеп торганда язарга; үзе төзегән һәм тәкъдим ителгән текстны тикшерергә, орфографик һәм пунктуацион хаталарны табарга һәм төзәтергә өйрәнә.

Укучы орфографик хата ясау мөмкинлеге булган очракларны аңлау, аерым орфограммаларга мисаллар сайлау, текстлар төзегәндә орфографик һәм пунктуацион хаталарны булдырмау өчен, язганнарны үзгәртү, хаталар өстендә эшләгәндә, аларның сәбәпләренә төшенү һәм алдагы язма эшләрдә хата җибәрмәү юлларын ачыклау мөмкинлеге ала.

**Сөйләм үстерү**

Бу бүлектә укучы: аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга; көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес кулланырга; аралашу ситуациясен исәпкә алып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә; текстка исем бирергә; укылган яки тыңлаган текстның планын төзергә; аерым аралашу ситуацияләренә туры китереп, хат яки тәбрикләү хаты кебек кечкенә текстлар язарга өйрәнә.

**Татар теленнән сәгатьләр бүленеше**

| № | Бүлекләр | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | **1-3нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау** | **8** |
| 2 | Сүз. Телнең сүзлек байлыгы.Сүзнең лексик мәгънәсе | **8** |
| 3 | **Сүз төзелеше** | **11** |
| 4 | **Исем** | **8** |
| 5 | Фигыль | **13** |
| 6 | Сыйфат | **7** |
| 7 | Алмашлык | **6** |
| 8 | Сан | **6** |
| 9 | Рәвеш | **5** |
| 10 | Кисәкчәләр | **2** |
| 11 | Бәйлекләр | **4** |
| 12 | **Сүзтезмә** | **2** |
| 13 | Җөмлә. | **10** |
| 14 | Текст | **8** |
| 15 | Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту. | **4** |
| | **Барлыгы** | **102** |

**Эчтәлек**

**<u>1-3 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. - (8 сәг.)</u>**
Аваз һәм хәреф. Сузык һәм тартык авазлар.Иҗек.Сүзләрне юлдан юлга күчерү. ь,ъ хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язуЯнәшә килгән бертөрле аваз хәрефләре булган сүзләр.Алфавит. Алфавитның әһәмияте.Сүзлекләр белән эш.Сингармонизм законы турында беренче күзаллау.

**<u>Сүз. Телнең сүзлек байлыгы.Сүзнең лексик мәгънәсе . – ( 8 сәг.)</u>**
Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Тотрыклы сүзтезмәләр, омоним, синоним антоним, фрозеологик әйтелмәләр сүзлеге белән эш. Күп мәгнәле сүзләр. Искергән һәм яңа сүзләр

**<u>Сүз төзелеше. –( 11 сәг.)</u>**
Кушымча.Кушымчаларның төрләре.Кушымчаларның ясагыч һәм төрләндергеч буенча ясалышы(кушма, парлы сүзләр)

**<u>Сүз төркемнәре . Исем–(8 сәг.)</u>**
Исем. Мәгънәсе, сораулары. Җөмләдәге роле Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр Ялгызлык исемнәрдә баш хәреф.Берлек һәм күплек сан формалары. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше.

**Фигыль –(13 сәг.**

Мәгънәсе. Сораулары. Барлык, юклык формалары Зат-сан белән төрләнүе. Хәзерге, үткән, киләчәк заманнар. Фигыльләрнең күп мәгънәлеге.Боерык фигыль. Фигыльнең нигезе дифтонгка тәмамлануы. (сау-савыйм, савыйк, савыгыз)

**Сыйфат – (7сәг.)**

Мәгънәсе,сораулары. Җөмләдә роле. Сөйләмдә әһәмияте. Сыйфат дәрәҗәләре, сыйфатның җөмләдәге роле. (аергыч, хәбәр)

**Алмашлык –(6 сәг.)**

Зат алмашлыклары. Җөмләдәге һәм текстагы роле. Сорау алмашлыклары.Килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы.

**Сан -(6 сәг.)**

Санның билгеләмәсе, сорауларымикдар саны, тәртип саны.

**Рәвеш –(5 сәг )**

Лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен белдерүе.Аның төрләнмәве.Төп синтаксик функциясе – хәл.

**Кисәкчәләр.( 2сәг)**

Да. дә. гына , генә. Та, тә, ук, үк, кына ,кенә кисәкчәләре. Сөйләмдәге роле. Аларның җөмләгә төрле төсмер өстәве.

**Бәйлекләр (4 сәг.)**

Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә йомгак ясау, системалаштыру.

**Җөмлә. (10 сәг.)**

**Сүзтезмә -2 сәг**

Сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү

**Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр. 2 сәг**

Җөмләнең баш кисәкләре.

**Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. 1 сәг**

Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аеру.

**Җөмләнең иярчен кисәкләре Аергыч 1 сәг**.

Аергычка билгеләмәне һәм аның белдерүен аңлату.

**Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. 1 сәг**.

Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең узара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнеше.Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

**Эндәш сүзләр. 1 сәг.**

Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре.

**Гади һәм кушма җөмлә. 2 сәг.**

Тезмә кушма җөмләләрдә һәм, ә, ләкин, әмма теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре.

**Текст. Бәйләнешле сөйләм. (8 сәг.)**

Текст.Тема.Текст өлешләре. Сөйләм этикасы. Хикәяләү, тасвирлау текстлары. Хикәяләү, фикерләү текстлары.

**Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту.(4 сәг.)**

## Календарь-тематик планлаштыру

| № | Дәреснең темасы | Үтәлү вакыты | | Эшчәнлек төре һәм формасы |
|---|---|---|---|---|
| | | план | факт | |
| **1-3 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. (8 сәг.)1** | | | | |
| 1 | 3 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. | 2.09 | | Үткәнне кабатлау |
| 2 | Җәйге истәлекләр буенча сочинение язу. | 5.09 | | Сочинение язу |
| 3 | Авазлар һәм хәрефләр. | 7.09 | | Практик эш сүзләрдәге орфограммаларны танып, аларның язылышын кагыйдәгә нигезләнеп аңлату |
| 4 | Авазлар һәм хәрефләр. | 9.09 | | |
| 5 | Тамыр һәм кушымча | 12.09 | | |
| 6 | Сүз төркемнәре | 14.09 | | Җөмләнең баш кисәкләрен табу, тест биремнәрен башкару |
| 7 | Үткәннәрне ныгыту. Тест биреме №1 | 16.09 | | |
| 8 | Кереш диктант. Сентябрь | 19.09 | | Кереш диктант Җөмләләрне, сүзләрне дөрес яза белү күнекмәләрен үстерү |
| **Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Сүзнең лексик мәгънәсе(8 сәг.)** | | | | |
| 9 | Сүзнең лексик мәгънәсе Хаталар өстендә эш. | 21.09 | | Лексик төшенчәсен аңлату,аңлатмалы сүзлекләр белән эш,хезмәтләрне бәяләү, төзәтү; татар теленең сүз байлыгы, сүзнең лексик мәгънәсе; лексик мәгънәгә туры килгән сүзләр табу |
| 10 | Алынма сүзләр. | 23.09 | | әйтелеш һәм язылыш, сүзлек запасын тулыландыру. |
| 11 | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. | 26.09 | | Сүзләрнең төрле мәгънә белдерүе |
| 12 | Тотрыклы сүзтезмәләр. | 28.09 | | Фразеологик әйтелмәләрне сөйләмдә куллану |
| 13 | Омонимнар | 30.09 | | Парларда эш,омонимнарны табу |
| 14 | Синонимнар, антонимнар. | 03.10. | | Синонимнар, антонимнарга мисаллар китерә белү. |
| 15 | Изложение язу. Усак. | 05.10. | | Укучыларның белем күнекмәләрен ныгыту |
| 16 | Үткәннәрне ныгыту.Текст өстендә эш .Тест биреме №2 | 07.10. | | Тест эшләү |
| **Сүз төзелеше (11сәг.)** | | | | |
| 17 | Тамыр һәм кушымча. | 10.10. | | Парларда эш,сүз байлыгы; төрле телләрдән кергән сүзләр, кулланылу өлкәсе |
| 18 | Сүз ясагыч кушымчалар. | 12.10. | | |
| 19 | Сүз ясагыч кушымчалар. | 14.10. | | Парларда эш,сүз байлыгы; төрле телләрдән кергән сүзләр, кулланылу өлкәсе |
| 20 | Сюжетлы рәсем буенча сочинение.”Җиләкле җәй” | 17.10. | | Модель буенча эш буенча эш |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 21 | Төрләндергеч кушымчалар. | 19.10. | | Рәсем һәм план буенча эш |
| 22 | Кушма сүзләр. | 21.10. | | Тартым, күплек һәм килеш кушымчалары<br>Парларда эш,сүзләрнең мәгънәләре,<br>Парларда эш, парлы сүзләр, аларның ясалышы һәм дөрес язылышы<br>Тезмә сүзләрне аеру, дөрес язу |
| 23 | Кушма сүзләр. | 24.10. | | |
| 24 | Парлы сүзләр. | 26.10. | | |
| 25 | Тезмә сүзләр. | 28.10. | | |
| 26 | Контроль диктант Тема: “Сүзнең лексик мәгънәсе” (“Хәлимә”) | 07.11. | | орфограммаларны кулланып, диктант язу, фигыль темасы буенча биремнәрне үтәү |
| 27 | Хаталар өстендә эш.Үткәннәрне ныгыту.Тест №3 | 09.11. | | Укучыларның алган белем һәм күнекмәләрен тикшерү |
| **Сүз төркемнәре. Исем. (8 сәг.)** | | | | |
| 28 | Сүз төркемнәре. Исем. | 11.11. | | исем төшенчәсе, мәгънәсе, сораулары ялгызлык төшенчәсе, төркемнәре, |
| 29 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | 14.11. | | |
| 30 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр.Сайланма диктант. | 16.11. | | Иҗади эш, ялгызлык төшенчәсе,төркемнәре, язылышы уртаклык төшенчәсе, язылышы, алган белемнәрне практикада куллан |
| 31 | Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. | 18.11. | | берлек һәм күплек сан формалары, берлек һәм күплек тартым кушымчалары |
| 32 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 21.11. | | |
| 33 | Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше | 23.11. | | |
| 34 | Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше.Тест | 25.11. | | |
| 35 | Изложение язу Хәйдәр коткарды. | 28.11. | | Изложение язу орфограммаларны кулланып изложение язу, сүз төркемнәрен билгеләү |
| **Фигыль (13 сәг.)** | | | | |
| 36 | Фигыль турында үткәннәрне искә төшерү. | 30.11 | | Хәзергезаман хикәя фигыльнең белдерелеше, сораулары, ясалышы, юклык төр кушымчалары, сөйләмдә аларны аера белү |
| 37 | Хәзерге заман хикәя фигыль. | 02.12 | | |
| 38 | Хәзерге заман хикәя фигыль. | 05.12 | | |
| 39 | Үткән заман хикәя фигыль. | 07.12 | | |
| 40 | Үткән заман хикәя фигыль. | 09.12 | | |
| 41 | Киләчәк заман хикәя фигыль. | 12.12 | | |
| 42 | Киләчәк заман хикәя фигыль. | 14.12 | | |
| 43 | Боерык фигыль. | 16.12 | | Таблицалар кулланып биремнәрне үтәү |
| 44 | Боерык фигыльнең төрләнеше. | 19.12 | | |
| 45 | Боерык фигыль. | 21.12 | | |
| 46 | Антоним һәм синоним фигыльләр. | 23.12 | | |
| 47 | Контроль диктант. Тема: “Фигыль” (Төлке) | 09.01 | | Контроль диктант орфограммаларны кулланып, диктант язу, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | фигыль темасы буенча биремнәрне үтәү |
| 48 | Хаталар өстендә эш. Тест биремнәрен башкару. | 11.01 | | Тест биремнәрен башкару |
| **Сыйфат (7 сәг.)** | | | | |
| 49 | Сыйфат турында үткәннәрне кабатлау. (2 кисәк) | 13.01 | | Сыйфат дәрәҗәләре төп (гади) , чагыштыру, артыклыккимлек, сыйфат дәрәҗәләренең ясалышы, аларның дөрес язылышы |
| 50 | Сыйфат дәрәҗәләре. | 16.01 | | |
| 51 | Сыйфат дәрәҗәләре. | 18.01 | | |
| 52 | Сыйфатларның җөмләдә аергыч һәм хәбәр булып килүе**.** | 20.01 | | |
| 53 | Синоним һәм антоним сыйфатлар. | 23.01 | | |
| 54 | Сочинение язу “Керпе”. | 25.01 | | Сочинение язу |
| 55 | Үткәннәрне ныгыту.Тест биреме. | 27.01 | | Тест биремнәрен башкару |
| **Алмашлык (6 сәг.)** | | | | |
| 56 | Зат алмашлыклары. | 30.01 | | Төркемдә эш,кагыйдәгә нигезләп,күнегүләр эшләү |
| 57 | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше. | 01.02 | | Төркемдә эш,кагыйдәгә нигезләп,күнегүләр эшләү берлек сандагы зат ал-машлыкларын килеш белән төрләндерү; дөрес әйтелеш һәм язылыш |
| 58 | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше. | 03.02 | | |
| 59 | Сорау алмашлыклары. | 06.02 | | |
| 60 | Сорау алмашлыклары.Тест биремнәре. | 08.02 | | |
| 61 | Аңлатмалы диктант “Аны һәркем ярата” | 10.02 | | Аңлатмалы диктант |
| **Сан (6 сәг.)** | | | | |
| 62 | Сан турында төшенчә. | 13.02 | | Хаталар өстендә эш<br>Белем һәм күнекмәләрне практикада куллану Сүзлекләр белән эшләү<br>Сан түрында беренчел күзаллау тудыру |
| 63 | Микъдар саны. | 15.02 | | |
| 64 | Микъдар саны. | 17.02 | | |
| 65 | Тәртип саннары. | 20.02 | | |
| 66 | Тәртип саннары.Тест биремнәре. | 22.02 | | |
| 67 | Искәртмәле диктант.” Чәүкә” | 24.02 | | Искәртмәле диктант |
| **Рәвеш (5 сәг.)** | | | | |
| 68 | Рәвеш турында төшенчә. | 27.02 | | төрле сүзләр янында килүе; текстта рәвешне таба белү, куллану |
| 69 | Телдә еш кулланыла торган рәвешләр, аларның дөрес язылышы. | 01.03 | | |
| 70 | Телдә еш кулланыла торган рәвешләр, аларның дөрес язылышы. | 03.03 | | |
| 71 | Изложение язу “Ябалак, тавык, аучы” | 06.03 | | Изложение язу орфограммаларны кулланып изложение язу, сүз төркемнәрен билгеләү |
| 72 | Рәвеш темасын ныгыту.Тест биреме. | 10.03 | | Тест биремнәрен үтәү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Кисәкчә (2 сәг.)** | | | | |
| 73 | Кисәкчәләр. | 13.03 | | Хаталар өстендә эш  Белем һәм күнекмәләрне практикада куллану Сүзлекләр белән эшләү |
| 74 | Кисәкчәләрнең сөйләмдә роле.Тест биреме. | 15.03 | | Тест биремнәрен үтәү |
| **Бәйлекләр (4 сәг.)** | | | | |
| 75 | Бәйлекләр. | 17.03 | | Бәйлекнең җөмләдәге роле |
| 76 | Бәйлекләр. | 20.03 | | |
| 77 | Контроль диктант Тема:”   Рәвеш Кисәкчә. Бәйлекләр” (Сугыш һәм яз) | 22.03 | | Контроль диктант орфограммаларны кулланып, диктант язу, биремнәрне үтә |
| 78 | Хаталар өстендә эш.Бәйлек темасын ныгыту. | 24.03 | | Теманы ныгыту,кабатлау |
| **Сүзтезмә.(2 сәг.)** | | | | |
| 79 | Сүзтезмә. | 05.04 | | сүзтезмә төшенчәсе, аларны аера белү, сораулар кую |
| 80 | Сүзтезмәдә сүзләр бәйләнеше.Аңлатмалы диктант. | 07.04 | | Аңлатмалы диктант |
| **Җөмлә. (10 сәг.)** | | | | |
| 81 | Җөмлә.Җөмләнең баш кисәкләре**.** | 10.04 | | Күнегүләр эшләү |
| 82 | Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр. | 12.04 | | Кагыйдәгә нигезләп күнегүләр эшләү хезмәтләргә бергәләп бәя бирү, хаталарны төзәтү; гади һәм кушма җөмлә төшенчәсен аңлату;   тиңдәш кисәкләрне табу, чагыштыру, аеру, куллану |
| 83 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. | 14.04 | | |
| 84 | Җөмләнең иярчен кисәкләре.Аергыч. | 17.04 | | |
| 85 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. | 19.04 | | |
| 86 | Эндәш сүзләр.Тест биреме. | 21.04 | | |
| 87 | Гади һәм кушма җөмлә. | 24.04 | | |
| 88 | Гади һәм кушма җөмлә. | 26.04 | | |
| 89 | Изложение язу. “Кечкенә умартачы” | 28.04 | | Изложение язу |
| 90 | Арадаш аттестация | 03.05 | | Тест биремнәрен үтәү |
| **Текст.  (8 сәг.)** | | | | |
| 91 | Текст.Тема.Текст өлешләре. | 05.05 | | Текстны уку,төп фикерне билгеләү әдәпле мөгаләмә таләпләренә туры китереп аралаша белү; |
| 92 | Текст.Тема.Текст өлешләре. | 08.05 | | |
| 93 | Сөйләм этикасы. | 10.05 | | |
| 94 | Сөйләм этикасы. | 12.05 | | Күнегүләр эшләү |
| 95 | Хикәяләү, тасвирлау текстлары. | 15.05 | | Һәр абзацка исем кую, план төзү,эчтәлек сөйләү,орфограммаларны табу,эчтәлеген язу |
| 96 | Хикәяләү, фикерләү текстлары. | 17.05 | | |
| 97 | Контроль диктант Тема:”  Җөмлә.  Текст“ (Җырчы кош) | 19.05 | | Контроль диктант Ел буена үткән белем һәм күнекмәләрне ныгыту |
| 98 | Хаталар өстендә эш. Сурәтләү һәм хикәяләү | 22.05 | | Һәр абзацка исем кую, план төзү,эчтәлек |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | текстлары | | | сөйләү,орфограммаларны табу,эчтәлеген язу |
| **Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту. (4 сәг.** | | | | |
| 99 | Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту. | 24.05 | | Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, тест һәм күнегүләр эшләү |
| 100 | Үткәнне ныгыту | 26.05 | | |
| 101 | Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту .Тест биремнәре | 29.05 | | Тест биремнәрен үтәү Хаталар өстендә эш<br>Белем һәм күнекмәләрне практикада куллану Сүзлекләр белән эшләү. |
| 102 | Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту.Йомгак. | 31.05 | | |

**Укыту –методик комплекты:**


1.Татар теле 1 кисәк, 2 кисәк дәреслек И.ХМияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова “ Мәгариф - вакыт” нәшрияты 2014 ел
2. И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова Методик кулланма “Мәгариф - вакыт” нәшрияты 2014 ел
3. Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар. 1-11 нче сыйныфлар Казан Татар. китап. нәшрияты 2011 ел
4. Татар теленнән диктантлар: Дүртьеллык башлангыч мәктәп. 1-4 сыйныфлар өчен: Укытучылар өчен кулланма/М.Х Хәсәнова, Л.И. Галиева, С. С. Мөхәммәтшина, Т.Н. Садыйкова. - Казан: Мәгариф, 2000ел.
5. 1-4 сыйныфлар өчен язма эшләр.Төзүчесе: М.А.Вәлиуллин. Казан 2009

**Кушымта**

**4 нче сыйныф укучыларының татар теленнән белем, осталык һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары.**

2-4 нче сыйныфларда татар теленнән язма эшләр ике төркемгә бүленә:
- өйрәтү эшләре (изложение, сочинение);
- контроль эшләр (күчереп язу, сүзлек диктанты, диктант).

1—2 нче сыйныфларда аерым җөмләләрне яки бәйләнешле текстны үзгәрешсез күчереп язу таләп ителсә, 3—4 нче сыйныфларда сүзләрне кирәкле формада куеп яки нокталар урынына туры килгән сүзләрне куеп күчереп язу эшләре кулланыла.

Диктант яздыру өчен, төрле характердагы тел материалы (аерым сүзләр, аерым җөмләләр, бәйләнешле текст) сайланырга мөмкин. Диктант яздыру өчен сайланган бәйләнешле текст уртача авырлыкта, эчтәлеге һәм грамматик төзелеше ягыннан укучыларга аңлаешлы булырга тиеш, ә инде үзләштерелмәгән сүзләр очраса, укытучы аларны тактага язып аңлата.

Укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен тикшергәндә, эчтәлекнең тулылыгына һәм эзлеклелегенә, җөмлә калыпларының грамматик яктан дөреслегенә һәм төрлелегенә игътибар итәргә кирәк. Язма эшләрнең эчтәлеген бәяләү белән беррәттән, укытучы орфографик һәм пунктуацион хаталарны да төзәтергә тиеш. Күп эшләрдә бер ук төрле хатакабатланса, бу кагыйдәне тагын бер тапкыр аңлату һәм дәрестә аңа махсус туктату сорала. Әгәр дә хаталар индивидуаль характерда булса, укучылар белән шәхси эш алып барырга кирәк.
1—2 нче сыйныфларда орфографик хаталарга гына игътибар ителсә, 3 — 4 нче сыйныфларда пунктуация хаталары да исәпкә алына. Хәрефне төшереп калдыру, кирәкмәгән хәреф өстәп яки хәрефләрнеалыштырып язу, сүзне юлдан-юлга дөрес күчермәү орфографик хатага карый. Әгәр дә сүз берничә урында дөрес, ә аерым бер урында хаталы язылган икән, бу ялгыш дип саналмый. Бер үк хата берничә сүздә кабатланса, бу бер ялгыш дип исәпләнә.

**Диктантны бәяләү**

Пөхтә һәм төгәл язылган, 1 орфографик хаталы диктантка «5»ле куела.
Пөхтә һәм төгәл язылган, 2—3 орфографик хаталы диктантка «4»ле куела.
Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4—6орфографик хаталы диктантка «3»ле куела.
Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 7 яки артыграк орфографик хаталы диктантка «2»ле куела.

**Язма сөйләмне бәяләү**

2—4 нче сыйныфларда укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен, өйрәтү характерындагы изложениеләр һәм сочинениеләр яздырыла. Аларны бәяләгәндә, эшнең эчтәлеге ягыннан тулы һәм эзлекле язылуы, грамоталы булуы исәпкә алына. Башлангыч сыйныфларда изложение һәм сочинениеләр өчен бер билге куела.
Эзлекле язылган, 1 орфографик һәм 1 пунктуацион яки 1 грамматик хаталы эшкә «5»ле куела.
Эзлекле язылган, ләкин эчтәлектә ялгыш җибәрелгән, 2—3 орфографик һәм пунктуацион яки 2—3 грамматик хаталы эшкә «4»ле куела.
Эзлекле язылмаган, 4—6 орфографик һәм пунктуацион яки 4—6 грамматик хаталы эшкә «3»ле куела.

Эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 7 дән артык орфографик һәм пунктуацион яки 7дән артык тупас грамматик хаталы эшкә «2»ле куела.

**Контроль күчереп язуны бәяләү**
Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә «5»ле куела.
Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1—3 төзәтүе яки 1—2 орфографик хатасы булган эшкә «4»ле куела.
Пөхтә һом төгәл язылмаган, 4—5 төзәтүе яки 3—5 орфографик хатасы булган эшкә «3»ле куела.
Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булган эшкә «2»ле куела.
(каллиграфик матур язу 2 юл).Орфографик хаталарга гына игътибар ителә; әгәр дә сүз берничә урында дөрес, ә аерым бер урында хаталы язылган икән ,бу ялгыш дип саналмый. Бер үк хата берничә сүздә кабатланса, бу бер ялгыш дип исәпләнә.

**Контроль сүзлек диктанты**
Пөхтә ,1орфографик хатасыз булса **“5”**ле;
пөхтә,2-3 орфографик хатасы булса **“4”**ле;
пөхтә язылмаган, 4-6 орфографик хатасы булса “3”ле;
пөхтә түгел, 7, артыграк хатасы булса “2”ле куела.

**Язма сөйләм** (изложение) күнекмәләрен үстерү өчен, өйрәтү характерында яздырыла, бер билге куела.Өйрәтү характерындагы язма эшләрнең уңай билгеләре генә журналга куела.
Бирелгән темага эзлекле язылган,1 орфографик һәм 1 грамматик хатасы булса **“5”**ле; эзлекле язылган,ләкин эчтәлектә ялгыш җибәрелгән, 2-3 орфографик яки 2-3 грамматик хатасы булса**”4”**ле;
эзлекле язылмаган, 4-6 орфографик яки 4-6 грамматик хатасы булса “3” ле,
эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 7дән артык орфографик яки 7дән артык тупас грамматик хатасы булган эшкә “2”ле куела

**Диктант**
Пөхтә ,1орф-к хатасы булса **“5”**ле;
пөхтә, 2-3 орф-к хатасы булса **“4”**ле;
пөхтә язылмаган, 4-6 орф-к хатасы булса “3”ле;
пөхтә түгел, 7, артыграк хатасы булса “2”ле куела.

**Күчереп язуны бәяләү**.
Пөхтә итеп язылган, орфографик хаталары булмаган, ләкин 1-2 җирдә хәрефләрнең урыны алышынган булса, “5”ле куела.
Эш бик үк чиста итеп башкарылмаса, 1-2 хата җибәрелсә, хәрефләрнең урыны алышынса, “4”ле куела.
Язуда 3-5 хата җибәрелсә яки хәрефләрнең урыны алышынса, текст пөхтә итеп язылмаса, төзәтүләр булса, “3”ле куела.
Хаталар саны 5 тән артса, төзәтүләр күп булса, “2”ле куела.

**Сүзлек диктантларын бәяләү.**
Хаталары булмаган эшкә “5”ле куела
2 хата, 1 төзәтелгән хата булса, “4”ле куела.
3 хата, 1 төзәтелгән хата булса, “3”ле куела.
5 хата булса, “2”ле куела.

**Тестларны бәяләү.**
Тестлар түбәндәгечә бәяләнә:
“5”ле – 95-100 % үтәлсә;
“4”ле – 80-94 % биремнәргә җавап бирелсә;
“3”ле – 51-79 % биремнәр үтәлсә;
“2”ле – дөрес җавап 51 % тан да кимрәк булса.

**Контроль эшне бәяләү**
Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә **«5»ле** куела.
Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1—3 төзәтүе яки 1—2 орфографик хатасы булган эшкә **«4»ле** куела.
Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4—5 төзәтүе яки 3—5 орфографик хатасы булган эшкә **«3»ле** куела.
Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булган эшкә **«2»ле** куела